# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлегенең Югары Юшады торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**25.11.2024ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юшады авыл җирлегенең Югары Юшады торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1.«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юшады авыл җирлеге Югары Юшады торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, тыл хезмәтчәннәре, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Югары Юшады торак пунктына Владимиров урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, килешү буенча түләү).

3.Әлеге карарны Юшады авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юшады авыл җирлеге башлыгы ____________ И.Р.Ханов